стных интересов, склонностей и особенностей обучающихся, отвечает требованиям современных образовательных стандартов и является эффективным.

*Литература*

1. Федеральный государственный образовательный стандарт основного общего образования / Федеральные государственные образовательные стандарты. - Режим доступа http://standart.edu.ru/catalog.aspx?CatalogId=2588

**Хуҗиәхмәтов Ә.Н.**

## МИЛЛӘТ ТЕЛЕ ҺӘМ ТАНЫП-БЕЛҮ ПРОЦЕССЫНДАГЫ ТЕЛГӘ БӘЙЛЕ ПСИХОЛОГИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘР

*Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан шәһәре*

Бүгенгесе көндә дөнья халыклары алты мең телдә аралашалар һәм сөйләшәләр. Тарихта үле телләр барлыгы да билгеле. Үлеп баручы телләр санын көннән-көн арта бара. Кешелекнең соңгы өч буын яшәү дәверендә ягъни 90 ел аралыгында 200 тел юкка чыкты. Бу безгә нәрсә белән куркыныч яный соң? Телнең үлеме белән сүзләрнең югалуы гына куркыныч янамый. Куркыныч тагын да зуррак. Тел белән бергә дөньяга карашлар тупланмасы, аралашу, кыйммәтле гыйлемнәр, тулы бер фикерләр дөньясы юкка чыга. Аның төп сәбәбә булып милләтләрнең (икътисад, сәясәт, мәдәният, фән, спорт, мәгариф һ.б.) үзара тыгыз аралашуы тора (интеграция). XXI гасырда 30% телләр юкка чыгар дип фаразлана.

Бүгенгесе көндә "Югалу куркынычы яный торган дөнья телләре атласы" китабы дөнья күрде. Бу китапта дөнья телләренә югалу куркынычы яный торган сәбәпләрнең бәяләмәсеннән чыгып барлык телләрдә биш категориягә бүленгән. Үлеп баручы телләр бүгенгесе көндә шундый халәтләрдә яшиләр:

- тотрыксыз хәлдә;
- куркыныч хәлдә;
- җитди куркыныч хәлдә;
- аяныч хәлдә;
- югалу хәлендә.

Бу классификациядән чыгып күзаллаганда телләрнең шундый халәтләрдә яшәгәнен күрербез: соңгы өч буын яшәешендә

- 200 тел юкка чыкты;
- 538 тел аяныч хәлдә;
- 502 телгә җитди куркыныч яный;
- 651 тел куркыныч астында;
- 607 тел тотрыксыз хәлдә яшәп киләләр.

Димәк моннан чыгып нинди нәтиҗә ясарга була соң? Дөнья халыклары телләренең 50% на үлем куркынычы яный.

ЮНЕСКОның генераль директоры Коитиро Мацууранынң әйтүенә караганда телнең үлеме үз артынан күп төрдәге рухи мәдәни мирасның юкка чыгуына китерә. Аларга бигрәктә кыйммәтле ганганәләр (традицияләр) мирасы һәм сөйләм телдәге халыкның авыз иҗаты керә.

Телләрнең үлеме үзе артыннан кешелек белән биологик төр арасындагы элемтәләрнең юкка чыгуына да китерә. Чөнки тел галәм, табигать өлкәсендәге гаять бай гыйлемнәрне саклый.

Телләр арасында паразит булган телләр дә бар. Әйтик инглиз, француз, испан һәм кытай телләре. Бу колониаль яаулау сәясәте вакытында колониаль телгә әйләнгән телләр. Алар башка телләрне үлемгә дучар иткән телләр.

Тeлллләрнең югалуын җир шарындагы нинди дә булса җәнлек һәм үсемлек төренең юкка чыгуы белән тиңләргә кирәк. Чөнки һәр тел ул үзенең эчке төзелеше булган фикерләр дөньясы, аның үзенә генә хас ассоциатив элемтәләр, метафоралар, фикерләү образы, сүзлеге, фонетикасы һәм грамматикасы бар. Шул сәбәпле үз законнары белән яши торган һәр тел күркәм архитектура төзелешен күз алдына китерә.

Америка тел белгече Э. Сепир XX гасырның 30 елларында лингвистик чагыштырмалылык тәгълиматын тәкъдим итә. Ул түбәндәгедән гыйбәрәт: тел төзелеше белән уйлау бәяләмәсе, тышкы тирәлекне танып-белү ысуллары арасында тыгыз һәм өзлексез элемтә яши. Чынбарлык дөнья аң аслыгында телнең норма һәм законнары җирлегендә төзелә. Телнең грамматикасы фикерне үзе тудыра. Кешенең фикерләү эшчәнлегенең программасы һәм идарәчесе булып тора. Кешенең фикерләү һәм кабул итүе аның кайсы телдә сөйләшүе белән бәйле. Әйтик, эскимосларда 20 гә якын сүз карның төрләрен аңлата, ә ацтеклар телендә карны, бозны һәм суыкны аңлатучы бер генә сүз бар. Шул сәбәпле ацтекларның кар сүзен күзаллау, кабул итүдә зур кыенлыклар туа. Америка индеецлары зуни телендә сары һәм коңгырт төсләрне аңлатучы сүзләр юк. Шул сәбәпле бу төсләрне кабул иткәндә, таныганда алар хата ясыйлар.

Телләр бер-берсеннән нәрсә дә булса да әйтү белән генә түгел, ә асылда җиңел әйтү белән аерылалар.

Америка тикшеренүчеләре Б.Берлин һәм В.Кэй 78 телне өйрәнеп шундый нәтиҗәгә киләләр. 11 төснең барлык телләр тарихында да үзләрен белгертә тоган кодлары барлыгын ачыклыйлар. Башта телләрдә ак һәм кара төсләр барлыкка килә. Аннан соң кызыл төс атамасы хасил була. Алга таба сары һәм яшел төсләр. Әгәрдә телдә алты төс атамасы бар икән, аларда җиденче зәңгәр төсне аңлатучы сүз дә бар. Әгәрдә телдә җиде төсне белгертүче сүздә бар икән, аларда коңгырт

төсен аңлатучы сүз була. Әгәрдә телдә сигезенче һәм анан да күбрәк төсләрне аңлатучы сүзләр дә бар икән, димәк шәмәхә, аксыл, күк, кишер (әфлисун) төсләре хасил була. Мәсәлән, борынгы чор тарихында грекларда өч кенә төс классификациясе була: ак, кара, кызыл, ә Яңа Гвинеянең дани халкы телендә төсләр ике сүз белән генә билгеләнә: мили – караңгы, салкын; һәм мола – якты, җылы. Кешеләр үз телләрендә төсләрне билгели торган төсләр булса аларны җиңел һәм хатасыз кабул иткәннәр, ятлаганнар. Бик хәҗәте булган очракт телдә бу төсне аңлата торган сүз булмасада ул төсне аерганнар һәм хәтергә сеңдергәннәр.

Менә шул сәбәпле татар телендә ак, кара, кызыл, яшел, сары, аксыл-сары, кызгылт-көрән, соры, ап-ак, куе яшел, караңгы яшел, ачык яшел, коңгырт, аксыл, шәмәхә, җете кызыл, алсу, күк, зәңгәр, кишер төсләре бар. Билгеле без аларны санап бетердек дип уйламыйбыз. Инде санаган-нарыннан чыгып шундый нәтиҗә ясарга була. Төсләрне билгеләүче никадәр күп сүз бар икән ул телнең бай булганлыгын, кайсыдыр хаҗәттә, аның камил тел булган-лыгын да аңлата. Димәк, татар теле камил телләрнең берсе.

*Тел* – милләтләрнең аларашуы өчен мөһим булган аваз һәм тамгалар җыелмасы.

*Ана теле* – кеше тумыштан үзләштергән бер төрле аваз һәм тамгалар җыелмасы.

Дөньядагы телләр арасыннан *универсаль телләргә* түбәндәге телләр керә: кытай, инглиз, рус, испан, хинди, япон, португал, гарәп, французтатар, немец, италян, бенгал, урда. Телчеләрнең фаразлауларына караганда бу 14 телне беләгән кеше җир шарындагы 70% халык белән аралаша ала.

Халыкара һәм милләтләрара аралашу телләренә тәбәндәге телләр керә: кытай, инглиз, рус, испан, гарәп, французтатар.

Торо тегу телендәге менә бу мисал моңа ачык дәлил булыр. Бу телдә шундый чагыштыру яши: таш – катып калган сүз, су – көлә торган сүз, чәчелгән орлык – вәгъдә итеп әйтелгән сүз. Безне чолгап алган барлык әйберләр – барда сүз. Сүз тауның өске өлешендә туа. Матур, түгәрәк һәм юка ташлар – болар ташка әйләнгән, катып калган сүзләр. Су – көлә торган сүз; күк – аның ерак образы; болытлар – аның җимеше, ә яңгыр – аның шатлыктан кычкырган тавышы. Чәчелгән орлык – вәгъдә итеп әйтелгән сүз. Әгәрдә чәчүче җырлый икән ул уңдырышлылыкны арттыра. Җирне тәпке һәм җыр белән эшкәртәләр.

Бу тау халкының күзаллауынча тауның биеклеге сүзнең көчен күрсәтә. Таудан далага төшкән сүз үзенең көчен югалта. Бу халыкның исемедә сүз белән бәйле. Алар үзләрен торо тегу ягъни тау сүзе дип атаганнар.

Бу халык сүзләрнең сафлыгын, телнең чисталыгын һәм уңдырышлылыгын авыл хуҗалыгы алымнары, йолалары белән саклыйлар. Бөтен ыру бик тыгыз аралашып яши торган 6-8 кешелек төркемнәрдән тора. Алар көнгә бер мәртәбә барсы бергә гомуми ашка җыелалар. Бер төркем амбарлар өчен җавап бирә (амбар – “сүзләр саклый торган урын”), икенче – яңгыр чакыру йоласы, өченчесе – кыядагы тау сукмагының торышы өчен һ.б. Билгеле ки, һәр төркемнең хөрмәт иткән үз табыну аксакалы бар. Һәм һәр төркем бөтен ыру өчен эшли.

Җир шарында һәр айда ике тел юкка чыгып бара. Рәсәй Федерациясенең Себер регионында яшәүче 30 лап телне дә шушы язмыш көтә. Боларның сәбәбе дә интеграция һәм алып барылган сәясәт күренеше. Рәсәй Федерациясендә яши торган 193 телнең фәкать икесе генә универсаль телләр рәтендә санала. Алар рус һәм татар телләре. Рус теле дәүләт теле рәтендә. Аның юкка чыгуына куркыныч янамый. Ул дәүләт тарафыннан якланган. Ә калган 193 телнең язмышы ничек? Аларны ни көтә?

“Рәсәй Федерациясе халыклары телләре” законы калган 193 телнең саклануына һәм үсешенә ышаныч күрсәтми (гарантия бирми). Бу закон маддәләрендә аларны яклау, саклау механизмы да һәм программасы да каралмаган.

Кеше һәм кешелек җәмгыяте турындагы яшь буынга тапшырылып килгән гыйлемнәргә туган тел, тарих, халык фәлсәфәсе, зәвык, педагогика һәм психология турында төрле мәгълүматлар керә.

Сөйләм теленә ия булу балага тапшырылып килә торган гыйлемнәрне үзләштерүдә төп нигез булып тора. Туган тел аша яшь буынга халыкның бай рухи мәдәнияте, дөньяны танып белүе, идеаллары, озак еллар буе тупланган гыйлем һәм тормыш тәҗрибәсе тапшырыла. Туган тел балаларга укыту-тәрбия бирүдә, аларда әхлак нормалары формалаштыруда мөһим чара булып тора.

Балаларның тел байлыкларын үстерүдә өлкәннәр (әти-әни, әбибабай) сөйләгән әкиятләр, бишек җырларының әһәмияте зур.

Ана баласы белән әле аның теле ачылганчы ук сөйләшә башлый. Моның әһәмияте шунда: балалар әниләренә охшарга тырышалар, сүзләрне отып калалар. Аларның тел һәм акыл үсешендә балалар авыз иҗаты да шактый зур әһәмияткә ия.

Татар милләте педагогикасы тәҗрибәсендә балаларның сөйләм телендәге сүзләр, хәреф һәм авазлар әйтүдәге җитешсезлекләрне (сакаулык, тотлыгуны) бетерү өлкәсендә халык тәҗрибәсендә тупланган гыйлемнәрне куллану уңышлы нәтиҗәләр бирә. Бу кимчелекләрне бетерү максатыннан милләт педагогикада тизәйткечләрдән файдаланалар. Кече яшьтәге балалар бигрәк тә [к], [г], [р], [ж] авазларын авырдан әйтәләр. Тизәйткечләрдә күбесенчә менә шул авазлар катнаша да инде.

Сөйләмдәге хаталарны төзәтү максатыннан чыгып, балалар белән күп авазлар катнашкан озын сүзләрне кызу-кызу әйтү күнегүләрен эшләргә кирәк. Балаларны хезмәт шартларында тәрбияләү күпкә нәтиҗәлерәк. Әлеге тизәйткечләрнең күпчелегенең хезмәт процессында тууын ассы-зыклап үтәргә кирәк.

Балаларның сөйләм телен үстерүдә шулай ук сәхнәләштерелгән балалар уеннары да яхшы нәтиҗәләр бирә. Үзләре башкарган драма уеннарында балалар нинди дә булса персонаж буларак катнашалар. Мәсәлән, "Кабак", "Алырмын кош", "Аксак мәче", "Аксак төлке", "Тел алыш", "Почмак алыш" һ.б.

Балаларның рольләргә кереп кара-каршы сөйләшүләре дидактик яктан да югары бәяләнә. Алар аерым бер персонажны аңа охшатып уйнарга тырышалар. Күп кенә башлангыч белем бирү ысулнамәчеләре, мөгаллимнәре һәм хәзерге мәктәп тәҗрибәсе шулай ук бу ысулга зур игътибар бирә.

Сәхнәләштерелгән уеннарда персонаж исеменнән сөйләү истә калдыру сәләтен яхшыртуда, акылны камилләштерүдә, сөйләм телен үстерүдә, сәнгатьлелеккә ирешүдә мөһим чара булып тора һәм бу өлкәләрдәге күнекмәләрне ныгыта.

Халык авыз иҗаты – ул халыкның телдән тарихи елъязмасы. "Рус-француз сугышы бәете", "Япон сугышы бәете" һ.б. бәетләрдә татар халкының туган иленә булган тирән хөрмәт вә ярату хисләре турында әйтелә. Аларда аерым шәхесләргә карата да, тарихи вакыйгаларга да халык тарафыннан бәяләмә бирелә.

Милләтнең күп буыннар тарафыннан гасырлар дәва-мында тупланып килгән тормыш зирәклеге, тапкырлыгы халык өйрәтүенең эчтәлеген баета, тулыландыра. Педагогик әһәмияткә ия булган татар халык экиятләрендә, мәкаль, әйтем, җыр, табышмак, бәет һәм легенда, дастан, эпосла-рында халыкның дөньяга карашы ап-ачык чагыла.

Кайбер дидактик мәсләкләрнең әһәмиятен аңлауда милләт психологиясе зур уңышларга ирешкән. Әйтик, эзлеклелек вә тупланмалылык. Укыту-өйрәтүдә ашыгырга ярамавын, укытуда һәркемнең аңына барып җитәрлек эзлеклелекне сакларга кирәклеген халык яхшы аңлаган. "Көчең җитмәгән ташка тотынма", "Барын да эшлим дигән берен дә эшли алмас", "Берьюлы күпкә кулың сузсаң, берсен дә тота алмассың", "Күпне кочаклаган аз учлар" һ.б. татар халык мәкальләрендә шул хакта сүз бара.

Күп кенә халык мәкальләре уку, гыйлем эстәрү өлкәсендә җыелмалылыкның мөһимлеген искәртәләр. Мәсәлән, "Аз белмәгән күп белмәс", «Әкрен барган ерак барыр, йөгергән артта калыр", "Тырышкан тамчы ташны тишкән" һ.б.

Күрсәтмәлелек. Гыйлем үзләштерүдә күрсәтмәлелек һәм шәхси тәҗрибәнең әһәмияте бәя биреп бетергесез. "Күпне күргән күп белер", "Ышанма кеше сүзенә, ышан үз күзеңә», "Ике тапкыр ишетүдән бер

тапкыр күрү яхшы" һ.б. Бу мәкальләр күрсәтмәлелек мәсләгенең балаларны укыту процессындагы һәм, гомумән, дөньяны танып белү процессындагы зур әһәмиятен раслый. Тирән гыйлем үзләштерүдә кешедән аңлы эшчәнлек һәм активлык таләп ителә. Бу хакта балаларга: "Укыдым дип әйтмә, аңладым дип әйт», - диләр. Шәкертләрнең мөстәкыйль фикерләвенә тиешле нәтиҗә ясалырга тиеш: "Кеше акылын ишет, үз акылың белән эш ит". Милләт психологиясендә, кеше яшь чагында гына түгел, ә бөтен гомере буе яңадан-яңа гыйлемнәр үзләштерергә, аларны үзенең тормыш тәҗрибәсендә куллана белергә тиеш, дигән фикер зур кыйммәткә ия. "Мең ел яшә, мең ел өйрән", "Җиде йортның телен бел, җиде төрле белем бел", "Бер савыт та куләменнән артыкны сыйдырмый, гыйлем савыты гына күпме салсаң да киңәя бара", "Гыйлем күп – гомер кыска" һ.б.

Кабатлау, күнегүләр. Тирән, ныклы, төпле гыйлем үзләштерүгә кабатлау һәм күнегүләр нәтиҗәсендә ирешелә: "Чәйнәмәсәң йота алмассың", "Ун кат укы, бер кат яз". Бу өлкәдә шәкертләрнең хәтер мәдәниятенә аеруча зур игътибар бирелә. Күпчелек уеннар шактый катлаулы кагыйдәләрне, җыр текстларын истә калдырырга, хәтерне ныгытырга, яхшыртырга ярдәм итәләр. Кече яшьтәге балалар аларны өлкәнрәкләрнең уеннарын күзәткәндә күңелләренә сеңдереп, хәтерләп кала. Ишетү, истә калдыру һәм экият сөйләү шулай ук хәтер ныклыгын үстерә, аны камилләштерә. Милләтебез психологиясендә балаларның сөйләмен, хәтерен яхшырту өчен кулланыла торган һәм истә калдыру максатыннан иҗат ителгән шактый озын шигъри хикәяләр бар. Хәтердә калдыру мәдәнияте уеннар вакытында үстерелә, камилләштерелә.

Акыл тәрбиясе өлкәсендә башка ысул һәм алымнар да киң кулланыла. Танып белүгә корылган уеннар, күзәтүләр, кабатлау күнегүләре, балаларның укуга аңлы карашын үстерү һ.б. ысуллар уңышлы кулланыла.

Күзәтүчәнлекне үстерү. Баланың күзәтүчәнлек сәләте аларның көндәлек тормыш нәтиҗәсендә үсә. Әйтик, "Нинди агач җилсез шаулый?" (Усак) кебек табышмаклар яшьләрдә күзәтү мәдәниятен үстерүгә ярдәм итәләр. Күп кенә татар халык экиятләренең ахыры шаяру, уйдырма характерында бетә. Алар шулай ук балаларны күзәтүчәнлек, игътибарлылыкка һәм мөмкин булган чын вакыйгаларны уйдырмалардан аера белергә өйрәтә.

Татар милләте психологиясендә зирәклекне чуалткычлар ярдәмендә ныгытулар да гамәлгә кергән. Чуалткычлар балаларның сөйләм телен, уйлау сәләтен үстереп, баетып кына калмыйлар, ә бәлки әсәрдә нәрсәнең чынбарлык, нәрсәнең уйдырма, ялган икәнен аера белергә дә өйрәтәләр. Аларның игътибарын тиз арада төрле күренешләргә юнәлдереп, киеренке шартларда тиз генә уйларга мәҗбүр итәләр. Чуалткычлар акыл, уйлау сәләтен, күзәтүчәнлекне үстерүдә аеруча зур әһәмияткә ия. Монда бер предметның билгеләре икенче әйберләргә күчә.

Чуалткычлар балаларны ана телендәге синонимнар һәм антонимнарның үзенчәлекләрен төшенергә, аларны урынлы куллана белергә өйрәтә, уйлау сәләтләрен үстерә (анализ ясау, чагыштыру, каршы куюh.б.).

Ата-аналарның роле. Балаларга акыл тәрбиясе бирүдә ата-аналар һәм гаиләдәге башка өлкәннәр зур роль уйный. Күп кенә татар халык әкиятләре тормыш иткән зирәк картларның, үлем сәгатьләре җиткәч, тормыш тәҗрибә-ләрен, белемнәрен балаларына васыять итеп тапшырулары белән башланып китә. Тылсымлы әкиятләрдә, гадәттә, атасы мирас итеп улларына кылычын һәм нинди дә булса берәр тылсымлы әйберен биреп калдыра. Әтисеннән әлеге мирасны кабул итеп алган һәм аталарының зирәк киңәшләрен истә тоткан уллры, кызлары тормышта, көрәштә зур уңышларга ирешә. Ә этиләренең һәм аксакалларның киңәшләрен тотмаган угыллар һәрвакыт, тормышта да, көрәштә дә уңышсызлыкка очраганнар, халык аларны үткен тәнкыйтьләгән.

Гомумән, әкиятләр үзләреннән-үзләре өлкәннәрнең күпьеллык тормыш тәҗрибәләрен, зирәк акылларын яшь буынга тапшыру чарасы булып тора. “Зирәк карт”, “Мәгънәле кыз”, “Уңган егет”, “Тапкыр кыз”, “Карт белән ялкау егет” h.б. әкиятләрдә яшьләргә гыйлем бирү өлкәсендә зур әһәмияткә ия булган күп кенә файдалы киңәшләр бар.

Әкиятнең төп герое, бернинди кара көч тә җиңә алмый торган уңай герой – халык үзе. Ул һәр әкияттә диярлек, исемсез герой сыйфатында яки таз малай, хезмәтче, уңган кыз образларында катнашып, тормышның начар, тискәре якларын, халыкка карата начарлык кылучы тискәре геройларны, явыз патша һәм яшәргә комачаулык итүче һәртөрле кара көчләрне аяусыз камчылый, күпчелек очракта исә бөтенләй юк итә.

Халык әкиятләрендә хезмәт ияләренең уңай образлары барлык караңгы көчләргә каршы, дөреслек, гаделлекне өскә чыгару, кимсетелгәннәрне яклау, явызлыкны, җәберне җиңү өчен көрәшәләр. Алдар таз, Шомбай, хезмәтчеләр һәм ярлы егетләр, хезмәт ияләренең тормыш тәҗрибәсенә, акыл байлыгына таянып, табигатьнең гади халыкка яшәргә комачаулаган һәртөрле һәлакәт очрагын, шулай ук кешеләрнең чын дошманнарын, башкалар хезмәте исәбенә яшәүче сорыкортларны һәрвакыт җиңеп чыгалар. Бу көрәшләрдә халыкның батырлыгы, тапкырлыгы, зирәклеге, нинди генә кыенлыклар алдында да тез чүкмәслек булып чыгуы гәүдәләнә.

Рәсәй хөкүмәте дәүләти белем бирү стандарты төшен-чәсен һәм корылышын үзгәртүгә юнәлдерелгән “О внесении изменений в некоторые законодательные акты Российской Федерации” дип исемләнгән 448303-4 санлы федераль законны дөньяга чыгарды. Тәкъдим ителгән закон, чынлыкта белем бирү оешмасының компонентын һәм милли-төбәк компонентын юкка чыгарып, дәүләт стандартында 3 компонентлы корылыштан бер генә компонентлыга күчүне күз уңында тота.

Закон алга сөргән дәүләти белем бирү стандарты төшенчәсен һәм корылышын үзгәртеп тормышка ашыру Рәсәй Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешләре хокукларын чикләүгә, ана телләрне һәм әдәбиятны укытуны бетерүгә, милли мәктәпләрдә һәм милли-мәдәни компонентлы мәктәпләрдә милли мәдәният белән үз халкы тарихын өйрәнүне юкка чыгаруга илтә.

Кайбер төбәкләрдә бу канун моңарчы яшәп килгән милли мәктәпләрнең һәм милли-мәдәни компонентлы мәктәпләрнең ябылуына китерде, һәм ул дәүләт тарафыннан яклау табачак, – ахыр чиктә, Рәсәйдә милли белем бирү тупланмасына җеназа укылачак. Нәтиҗәдә мондый шөгыльләр милли телләрне һәм мәдәниятләрне саклау мәсьәләсендә җитди проблемалар тудырды.

Моннан тыш, бу канунның концепциясе Россия Федерациясе Конституциясенә турыдан-туры каршы килә, анда 68 нче маддәнең 3 нче пунктында болай диелгән: "Россия Федерациясе барлык халыкларга да туган телләрен саклауны, аны өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыруны гарантияли". Мондый хәл мәгариф өлкәсендә федерализм мәсләген кире кага.

Канунда аңарда күрсәтелгән төп белем бирү програм-малары федераль дәүләти мәгариф стандартын "милли-төбәк үзенчәлекләрне" искә алып гамәлгә кертеләчәк дип әйтелгән әйтелүен. Әмма канун концепциясенә нигезләнгәндә, ягъни дәүләти мәгариф стандартында милли-төбәк компоненты булмаганда, моны тормышка ашыру мөмкин түгел.

Бүгенге дөнья мәгариф киңлегенә белем бирүдә дә чагылыш тапкан этномәдәни процесслар белән мәдәнияттәге бердәйләшү процессларына каршылык хас. Фикеребезчә, бүгенге Рәсәйдә заманыбызны сыйфатлап биргән һәм мәдәниятне интернациональләштергәндә, милли үзаңның үсүеннән гыйбарәт булган "этниклык парадоксы" дип аталган күренешкә тап булабыз.

РФның мәгарифтәге Милли доктринасында буыннан-буынга тарихи күчә бару, телләргә хөрмәт белән карау, милли мәдәниятләрне саклау, тарату һәм үстерү, Россия халыкларының тарихи һәм мәдәни мирасына сакчыл караш тәрбияләү кирәклеге әйтелгән.

Милли мәктәпләрне үстерү – бу сәясәтне тормышка ашыруның мөмкин булган бер варианты. Тормышта мәгълүм бер милли мәдәниятнең үзенчәлеген мәктәптә белем бирүнең эчтәлегендә һәм рәвешендә чагылуны гадәттә милли мәктәп белән бәйлиләр.

Россиядә 193 милләт белән этник төркем булуы мәгълүм, һәм алар барысы да теге яки бу күләмдә мәгариф корылышында урын ала. Башкортостан Җөмһүрияте Мәгариф министрлыгының бер программасында "милли мәктәп" төшенчәсенә киңәйтелгән билгеләмә бирелгән.

Милли мәктәп – милли мәдәният учагы булган, мәдәниятләр арасында цивилизацияле диалог алып барырдай мәктәп, укучыларны милли мәдәниятләрнең тышкы формаларына гына түгел, рухи нигезләренә дә тарта.

Бүгенге көнгә түбәндәгеләр мөһим булып торалар: хәзерге шартларда милли мәктәп нинди булырга тиеш һәм ул уңышлы эшләсен өчен нинди шартлар кирәк? Иң әүвәле, милли мәктәп милли мәдәният кыйммәтләренә нигезләнергә тиеш, ягъни аның эшчәнлеге Адольф Дистервег тарафыннан расланган мәдәният ярашлылыгы мәсләге алып торырга тиеш. Мәдәният ярашлылыгы мәсләген гамәлгә кертү бөтен белем бирү һәм тәрбия процессын мәдәниятнең төрле элементлары белән тулыландырылуын таләп итә.

Бу парадоксны тәшкил иткән даими булмаган төрле зурлыклар арасында, мәгарифкә, мәктәпкә һәм гаиләгә шактый зур авырлык төшә. Милли мәдәниятне, телне, әхлакый, зәвык кыйммәтләрне үзләштерү нигезләре, халык рухы, ментальлек, милли үзаң нәкъ шунда формалаша да.

Социалистик рухтагы идеологиянең җитмеш еллык хакимлеге милли үзаң өчен чын фаҗига иде. Аның коточкыч эретелүе – ватан тарихын, фәлсәфәсен, шактый күләмдә матур әдәбиятны бозу һәм оныттыру хасыйл булды. Бу процесс зыялыларны, руханиларны юк итү, шулай ук эре милли музейлардагы байлыкны урлау һәм сату белән бергә барды. Болар барысы да бер генә максатка – милли мәдәниятнең чыганакларын юкка чыгарырга, Рәсәйне сәяси кирәклелектән чыгып, идарә ителердәй җансыз гәүдәгә әверелдерергә юнәлтелгән иде. Турысын әйткәндә, “үзгәртеп кору” барышында да, демократлар хакимияткә килеп, үзгәрешләр кертә башлагач та шушы ук әйбер күзәтелде.

Милли үзаңны торгызуга юнәлтелгән кечкенә генә омтылыш та кискен тискәре реакция тудырды. Кәефләренә күрә шаукымга ияреп, массакүләм чаралары милли үзаңны шовинизм, антисемитизм, хәтта фашизм белән тиңләргә тырыштылар. Вакытлы матбугат халыкның “коллык җаны”, руслар милли үзаң хакында бозык фикергә ияргәннәр, шулай булгач, аны торгызып маташмаска кирәк, дигән уйдырмалар белән тулды. Рус мәдәниятенең кайтарылмас югалтулары турындагы фикер йөртүләр кара йөрәклеләр тарафыннан XX гасыр башындагы рухи менталитет белән хәзерге чор арасында бернинди тәңгәллек куеп булмый, дигән сүзләр тууга юл ачты. Элеккеге вакыттагы кебек ачык рәвештә этник нигилизм һәм космополитизм алга сөрелә, Рәсәй мәдәниятен, тарихын хурлау һәм юк итү бара.

Чынлыкта без Рәсәй җәмгыятенең рухи тормышы үсеш-үзгәрешен “гомумкешелек кыйммәтләрен” алга сөргән интернациональ мондиал идеология [милләтләрне, дәүләтләрне инкяр итеп, гомуми дөньяви

тәртип кору] белән очрашабыз. Милли үзаңны формалаштырудагы юнәлешләрне күплеге арасында мәгариф тупланмасы аның аерым бер, әмма гаять мөһим өлешен тәшкил итә. Рәсәй халыклары менталитетына ят булган модельләр һәм концепцияләрне алу шул ук вакытта мәгарифне тулысынча миллилектән арындыруга китерергә мөмкин, хәер, китерде дә инде, ахыргача илебез педагогикасы ганганәләреннән (традицияләреннән) аерырга да мөмкин.

Нобель бүләге иясе, Австрия галиме Конрад Лоренц ганганәләрдән (традицияләрдән) аерылуны хәзерге кешелек дөньясының ярлыкалмаслык гөнаһасы дип атады. Бу бәя бүгенге көндә битләреннән күп кенә шәхесләр һәм мөһим тарихи вакыйгалар, мәшһүр Рәсәй язучыларының күп кенә әсәрләре сызып ташланган дәреслекләргә нигезләнгән Рәсәйдәге мәгариф тупланмасын чагылдыра.

Көнбатыш Аурропа педагогикасы тәҗрибәсе бөтенләй башка торышны сурәтли. Англия, Франция, Алмания, Италия, Испания мәгариф өлкәсендә милли мәдәнияткә ике куллап ябышканнар. Җәмгыяви-гуманитар белемнәрне өйрәнүдә алар үзләрендәге дин юнәлешләренә якын булган үз тарихларын, әдәбиятларын, телләрен, сәнгатьләрен, мәдәниятләрен өйрәнүгә өстенлек бирәләр. Мәктәп программаларының якынча 70%-ы милли мәдәният нигезләрен өйрәнүгә йөз тота. Табигать фәннәрендә дә, билгеле булганча, “инглиз физикасы”, “алман биологиясе” юк, аларда “инглиз физика”, “алман биология” һәм “француз математика” мәктәпләрен өйрәнүгә зур игътибар бирелә, илебез фәнни мәктәпләренең дөнья фәненә һәм мәдәниятенә керткән өлеше барлана.

Рәсәй – мең елдан артык мәдәнияте һәм тарихы булган дәүләт һәм җәмгыять. Үзенең кыйбласына күрә, ул милли рухи кыйммәтләргә ихластан дикъкать, шәхесне милли мәдәнияттән аермаслык торышны күрсәткән Көнбатыш илләренең тәҗрибәсен күбрәк куллана алыр иде.

Милли белем бирү һәм тәрбия идеясе К.Д. Ушинский, П.И. Ковалевский һәм В.Н. Сорока-Росинский иҗатларында тулысынча нигезләнгән иде. К.Д. Ушинский үзенең “Җәмгыять тәрбиясендә халыкчанлык турында” хезмәтендә түбәндәге нәтиҗәгә килә: “Общей системы народного воспитания для всех народов не существует не только на практике, но и в теории, и германская педагогика не более, как теория немецкого воспитания”. Ул, никадәр кызыктыргыч булса да, башка бер халык үрнәгендә яшәп булмаслыгына инанган иде, шулай ук, нинди генә төзек һәм җитди уйланылган булса да, ят бер педагогик тупланма нигезендә тәрбияләнергә мөмкин түгел. К.Д. Ушинский фикере буенча, иҗтимагый тәрбия тормыш мәсьәләләрен үзе хәл итми, үз артыннан тарихны да иярми, ә үзе аның артыннан иярә. Педагогика да, педагоглар да киләчәккә юл салмыйлар, моны халык үзе һәм аның алдынгы кешеләре эшли: тәрбия фәкать шушы юлдан бара һәм аерым шәхесләргә, яңа буынга шуннан барырга ярдәм итә.

К.Д. Ушинскийның милли педагогиканың төрле тупланмалары нигезендәге үзенчәлекле нигез мәсләкләр хакындагы уйланулары гаять кызыклы. Алман тупланмасы өчен, мәсәлән, бу – фән; инглизләрдә – холыкны ныгыту, ирекле үзидарә, гражданин идеалы; французлар өчен – туктаусыз алга омтылу, мәгарифнең яңа ысулларын һәм формаларын табу. Һәр халыкның кеше турында үз идеалы бар, һәм милли тәрбия тупланмасында ул шуңа омтыла да. Руслар әлегә тәрбия һәм белем бирүдә үз тупланмаларына ия түгелләр. Читләргә иярүдән ваз кичеп, халык рухына, омтылышларына җавап бирердәй үзеңнең милли тәрбия тупланмаңны булдырырга кирәк.

"Тәрбияләү – димәк, кешегә билгеле бер рухи сыйфатларны кертеп урнаштыру, ничек кертеп урнаштырырга, сеңдерергә – димәк, организмга аның туендыручы сүлләрен дә – физик, матди матдәләрне – кертергә кирәк. Милли рухта тәрбияләү – димәк, кешегә теге яки бу халыкка хас булган шундый ук рухи, рухани һәм хәтта физик сыйфатларны да кертү... Аннары, тәрбия теге яки бу халык яшәгән дин һәм дәүләт кысаларында алып барылырга тиеш. Тәрбияләү бу халыкның тарихына, холкына һәм үзенчәлекләренә тиң булырга тиеш".

Мәктәптә белем бирү тирәсендә Рәсәйдә килеп чыккан хәлне бер сүз белән бөтен мәгариф җыелмасын миллисезләндерү дип атарга мөмкин булыр иде. Шушының белән бәйле рәвештә милли-мәдәни оешмалар мәгарифнең югары стандартларына җавап бирердәй һәм милли ихтыяҗларны истә тоткан милли мәктәпләр булдыру юнәлешендә тукталмыйча эш алып баралар. Соңгы елларда гына да Рәсәйнең төрле төбәкләрендә гомуми белем бирә торган да, якшәмбе көн генә эшли торган татар, башкорт, чуваш, ар (удмурт), мукшы (мордва) мәктәпләре ачылды. Мондый шартларда заман тибындагы рус милли мәктәбен булдыру рус халкы алдына да мөһим бурыч булып килеп басты.